**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IIIчакырылыш)**

чираттан тыш утырыш
**КАРАРЫ**

20 гыйнвар 2020 ел **224** Теләче авылы

Теләче муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 04 апрелендәге 199 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турындагы кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте**:

1.Теләче муниципаль район Советының 2014 елның 4 апрелендәге «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турында кайбер норматив - хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында» гы 199 номерлы карарына (2014 елның 26 маендагы 210 номерлы, 2016 елның 15 ноябрендәге 67 номерлы, 2017 елның 20 апрелендәге 84 номерлы, 2017 елның 19 июлендәге 90 номерлы, 2018 елның 12 апрелендәге 127 номерлы, 2018 елның 24 августындагы 141 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 160 номерлы, 2019 елның 21 августындагы 185 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәдә:

1) 2 Бүлектә:

а) 8 статьяда:

- 1 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе

аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә, һөнәри берлек органында катнашудан тыш) шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, яллаучы вәкиленең Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре Советында, Муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек тарафыннан оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә кую тәртибен йә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр белән) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү (устав капиталында өлешләр белән);

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

– түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктын өстәргә:

«3.1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;".

1.2. 8 Бүлектә:

а) 26 статьяда:

- 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы буенча тиешле еллар эшләгән өчен пенсиянең максималь күләмен исәпләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи окладның максималь күләме (әгәр вазыйфаи оклад максималь һәм минималь әһәмияткә ия булса) кулланыла, ә классы чин өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгели торган норматив хокукый акты белән билгеләнгән билгеләмәдә исәпкә алына.».

1.3. 9 Бүлектә:

а) 30 статьяда:

- 3 өлештә «әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш»сүзләрен өстәргә.

б) 31 статьяда:

- 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Әлеге Нигезләмәнең 9, 10 һәм 30 статьяларында каралган түләтүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булу чорын, отпускта булуын исәпкә алмыйча, һәм коррупциячел хокук бозу кылган көннән алып өч елдан да соңга калмыйча, коррупциячел хокук бозу турындагы мәгълүмат кергән көннән алты айдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларда җинаять эше буенча җитештерү вакыты кертелми.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Башлыгы урынбасары — А. Г. Фәтхуллин